**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельной территории Зеленодольского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий по ликвидации и предотвращению заболевания высокопатогенным гриппом птиц, в соответствии со статьей 3[1] Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 27 марта 2006 года № 90 **постановляю:**

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения на территории птицеводческого предприятия, принадлежащего обществу с ограниченной ответственностью «Агрофирма «Залесный», расположенного по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский район, село Большие Ключи, улица Волостнова.

2. Ограничить на территории, указанной в пункте 1 настоящего Указа, в течение трех месяцев для всех владельцев птиц вывоз инкубационного яйца и живой птицы всех видов и возрастов в другие хозяйства.

3. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 9 ноября 2020 года № УП-734 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельной территории Зеленодольского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
25 декабря 2020 года
№ УП-875

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы Большие Ключи авылының Волостнов урамында урнашкан «Залесный» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кошчылык предприятиесе территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә өч ай дәвамында барлык кош-корт асраучыларга башка хуҗалыкларга яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Зеленодольск районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 9 ноябрендәге ПУ-734 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 25 декабрь
№ ПУ-875